Утверждаю

Директор МБОУ"Гимназия №1"
имени Мусы Джалиля
_____________ И.И.Хабибуллин

# “ТАҢ “
# балалар оешмасы программасы

# АҢЛАТМА ЯЗУЫ.

Проблеманың актуаллеге: укучылар үзидарәсе баланы мөстәкыйльлеккә, кешеләр белән аралашырга, карар кабул итәргә һәм кылган гамәлләр өчен җавап бирергә өйрәтү. Үзидарә үсеше өчен гомуми гимназия тормышына һәр сыйныфның да катнашуы һәм бердәм юнәлеш, үзәкләшкән җитәкчелек буенча эшләве мөһим. Педагогик коллектив үзидарә органнарының эшчәнлеген даими бәяли, иң катлаулы эшләрне башкарырга ярдәм итә.

УКУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНЫҢ ТӨП БУРЫЧЛАРЫ

1. Коммуникатив бурычлар. Яшүсмерләрне коллектив ярдәмендә тәрбияләү нигезендә тормышка ашырыла.
2. Регулятив (җайга салучы) бурычлар. Балаларның үз йөкләмәләрен башкарганда кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр җайга салына.
3. Иҗтимагый мөнәсәбәтләр:

иҗтимагый-җайлашу бурычлары укучыларның киләчәк тормышка мөмкин кадәр әзерлекле булуын күз алдында тота:

актуальләштерү бурычлары һәр баланың киләчәктә үзен көчле шәхес итеп тоя алачагына ышаныч булуын күзаллый: - иҗтимагый-юнәлеш бирү бурычлары балалар хәрәкәтләрендә катнашучы һәр кешегә эшчәнлекне, карашларны һ.б. ирекле сайлау мөмкинлеге бирә: иҗтимагый-төзәтү бурычлары "бала-җәмгыять" мөнәсәбәтләрен җайга салу, коллектив тарафыннан шәхесне, җәмгыять тарафыннан коллективны "төзәтү" өчен мөһим.

4. Оештыру бурычлары. Оешмага керүче баланың оештыру һәм иҗади сәләтен тормышка ашырырга ярдәм итә.
5. Тәрбияви бурычлар, һәрьяклы үсеш алган иҗади шәхес тәрбияләргә ярдәм итә.
6. Балалар оешмалары әгъзаларын иҗтимагый яклау бурычы.
7. Ял сәгатьләрен кызыклы һәм файдалы итеп оештыру бурычы.

"КАМА ТАҢНАРЫ" оешмасының әгъзалары булып:

1. " ТАҢ НУРЛАРЫ" - 1 -4 сыйныфлар
2. " ТАҢ" - 5-8 сыйфныфлар.
3. " СЕРДӘШ" - 9-11 сыйнфлар.

Программа 5 еллык.

1. " ТАҢ НУРЛАРЫ" төркеменә 1-4 сыйныф укучылары керә. Алар үз коллективларының тормышында, эшендә катнаша һәм аның:

а) туган җирне яратырга:

б) эшчән, тырыш булырга:

в) кыю, намуслы, көчле һәм ягымлы булырга

г) өлкәннәрне хөрмәт итәргә дигән кагыйдәләрен үти. Шигаре - " КӨН САЕН ЯХШЫЛЫК КЫЛ!" Вәгъдәсе

Мин,..........................................................................................................................

Яхшы әгъза булырга һәм оешманың кагыйдәләрен төгәл үтәргә вәгъдә бирәм. ҮСЕШ БАСКЫЧЛАРЫ Беренче баскыч - " АДЫМНАР" Бу баскычка басу һәм

ак тамга алу өчен чылбырда алты айдан да ким булмаган вакыт яшәргә, түбәндәге белем һәм һөнәрләрне үзләштерү зарур.

1. Оешманың кагыйдәләрен, девизны һәм шигарьне белү һәм аңлата алу.
2. Үз чылбырың, отрядың, флагың турында сөйли белү, үзара сәламләшү билгесен күрсәтү.
3. Йөгереп уйный торган өч уен, туплы өч уен уйный белү, өч бию һәм өч җыр өйрәнү.
4. Үзеңнең спорт күрсәткечләреңне белү.
5. Киселгәндә яки сыдырылганда, бөҗәкләр тешләгәндә, борыннан кан киткәндә беренче ярдәм күрсәтү.
6. Аптечканың кайда торганын белү. Кирәк булганда градусник кую, баш яки эч авртканда дарулар бирү.
7. Юл йөрү кагыйдәләрен үзләштерү, адашкан очракта нәрсә эшләргә кирәклеген белү. .
8. Икедән дә ким булмаган санда яңа һөнәр үзләштерү.
9. Җыеннарны калдырмау, соңарып килмәү. Пөхтә, таләп ителгәнчә киенеп йөрү.
10. Әти-әнигә булышырга тырышу. Торган җир турында ниндидер кызык яки гыйбрәт белү.
11. Сынаулар узу, кыюлыкны һәм җитезлекне сынау.

Икенче баскыч " БАШЛАНГЫЧ" Бер елдан да ким булмаган вакыт буе гимназиядә, җыеннарда активлык күрсәткән, әти-әнисенә теләп булышкан, ак тамгага ия булган һәм түбәндәгеләрне эшли белгән яңа баскычка күтәрелә һәм яшел тамга ала:

1. Үз чылбыры һәм отрядының традицияләрен белә, алар турында сөйли ала. Аңа бер эшне ике мәртәбә куелуның кирәге юк.
2. Сикереп уйный торган - биш, йөгереп уйный торган биш уен белә, атып мишеньга тидерә ала яки сикергеч бау белән оста сикерә.
3. Биш җыр һәм биш бию белә.
4. Спорт күрсәткечләрен яхшырта. Идәнгә ятып кулларында ун мәртәбә күтәрелә ала, сыңар аягында 20 метрны сикереп уза. Үзенең 60, 100 метрга йөгерүдәге, урыннан озынлыкка сикерүдәге, чүгәләү-торудагы күрсәткечләрен исендә тота.
5. Үзе торган җирнең уннан да ким булмаган төр кыргый хаванын атап бирә ала.
6. Үзе торган җирдә үсә торган агулы үсемлекләрне аера.
7. Урманда, табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белә. Сәяхәтләр оештыруның үзе уйлап тапкан төрләрен тәкъдим итә.
8. Үзе торган җирнең истәлекле урыннарын белә, үз шәһәренең кызыклы кешеләре турында иптәшләренә аңлата.
9. Кан киткәндә, кул яки аякка сөял чыкканда, җиңелчә пешкән чакта беренче ярдәм күрсәтә ала. Авыру кеше янына табип чакырта белә.
10. Республика флагының нинди икәнен, кайсы төснең нәрсә аңлатканын, флагны нинди очракларда күтәрергә икәнен белә.

11. Бик тиз киенә һәм чишенә, өс һәм аяк киемнәрен һәрвакыт чиста тота, чәчен почтә йөртә.
12. Тәкъдим ителгән өч һөнәрнең берсен, аңа өстәп тагын ике һөнәр йөрәнә.
13. Сынаулар уза: а) эзләүче (яшерелгән әйберне таба): б) энә тоту остасы: в) оста кул (ниндидер модель яки уенчык ясый).
Өченче баскыч "СУКМАКЛАР " Бу баскычка басу һәм кызыл тамга тагу өчен ике ел "Таң нурлары" оешмасы әгъзасы булып яшәргә һәм түбәндәге һөнәр һәм белемнәрне үзләштерергә кирәк:
1. Үз отрядының җырын, халык җырларын,аеруча үз төбәгендә туган җырларны белү.
2. Төн кунулы сәяхәткә чыгу өчен ниләр кирәген белү, әйберләрне дөрес итеп тутыру.
3. Гади төен төйнәү, биштәр тутырганда шул төенне куллану.
4. Сәяхәт өчен зарур булган куркынычсызлык кагыйдәләрен белү.
5. Суда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белү, 25 метр араны йөзеп узу.
6. Җәяүле сәяхәт өчен шәхси аптечка тутыру.
7. Күзгә чүп кергәндә, урман бете кадалганда, елан чакканда, очлы әйбердән яра алганда, пешкәндә беренче ярдәм күрсәтү.
8. Компасның төзелешен белү,аньщ нәрсәгә хезмәт итүен аңлата алу.
9. 15 төрле йорт хайванын яки кыргый хайванны тану яки эзләрен аера белү.
10. Агулы үсемлекләрне тану, шуларны ашап агуланганда беренче ярдәм күрсәтә белү.
11. Тәкъдим ителгән һөнәрләрнең берсен, аңа өстәп тагын ике һөнәр сайлап өйрәнү.
12. Сынаулар узу а) "Бренче ярдәм": б) "Учак хуҗасы": в) "Коллекционер".
"ТАҢ" оешмасына 5-8 сыйныф укучылары керә
Кагыйдәләре:
а) туган телеңне, халкыңны яратырга:
б) укуда һәм хезмәттә тырыш:
в) һәр җирдә ярдәмчел, миһербанлы:
г) өлкәннәргә һәм кечкенәләргә мәрхәмәтле булырга. Вәгъдәсе
Мин ..........................................................................................
үз теләгем белән "ТАҢ" төркеменә керәм, төркемнең законнарын төгәл үтәргә вәгъдә бирәм. Шигаре - " һәр көнне яхшы эшләр генә кыл" Беренче баскыч.
Беренче баскычны алу өчен төркем әгъзалары түбәндәгеләрне үзләштерергә тиеш:
1. Оешманың кагыйдәләрен, традицияләрен, шигарен, символларын белү.
2. Үз Республикаңның тарихын, өч халык җырын һәм биюен белү.
3. Оешманың символлары турында сөйли белү.
4. Гадәттән тыш хәлләрдә хәлиткеч карар кабул итә белү: -табипны, милиция һәм янгын сүндерү хезмәткәрләрен чакыру, беренче ярдәм күрсәтү.
5. Өстәл һәм хәрәкәтле уеннар оештыра белү.

6. Үз хезмәтен дөрес итеп оештыру, бурычларны дөрес итеп бүлү, аларның үтәлешен күзәтү.
7. Көнлек эш тәртибен дөрес итеп бүлү.
8. Кунакта, урамда һәм урманда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен белү һәм үтәү.
9. Торган төбәгенең табигатен, хайваннарын, кошларын яхшы белү.
10. Ике көнлек походта булу: дөрес итеп учак үрләтү һәм сүндерү:
- поход өчен биштәр тутыру:
- компастан файдалана белү:
- картадагы шартлы билгеләрне уку:
- кешенең, велосипедның, мотоциклның, автомобильнең, кошларның һәм хайваннарның кардагы эзләрен укый белү.
11. Сәяхәт вакытында куркынычсызлык кагыйдәләрен төгәл үтәү.
12. Кул эшләрен яхшы белү.
13. Ризык әзерли һәм өстәл кора белү.
14. 10 күнегүдән торган иртәнге гимнастика үткәрү.
15. Үзеңнең спорт нәтиҗәләреңне белү.
16. Үзең сайлаган бер һөнәрне үзләштерү.

ИКЕНЧЕ БАСКЫЧ 1. Республикада эшләп килүче балалар оешмалары турында
мәгълүматлы булу.
2. Республика һәм оешма символикасын дөрес файдалану.
3. Республика тарихын яхшы белү.
4. Табигатькә сакчыл караш һәм аны саклау буенча эш алып бару.
5. Алты халык җырын һәм бер халык биюен башкара белү.
6. Төп музыка һәм театр жанрларын белү.
7. Үз халкыңның мәдәниятен һәм сәнгатен белү.
8. Бер көнлек туристик сәяхәттә катнашу:
картаны уку:
карта һәм компас ярдәментә сәяхәтнең маршрутын билгеләү:
- палатка урынын дөрес сайлау, аны урнаштыру һәм үзеңә урын-җир әзерләү:
- урманда яңгырдан саклану урыны әзерләү:
- учак үрләтү , аны дөрес итеп сүндерү:
- ике кешелек азык әзерләү 9.Беренче ярдәм күрсәтә белү.
10. Шәхси гигиена таләпләрен яхшы белү һәм үтәү.
11. Тәмле итеп ризык пешерү, экибану яки чәчәк бәйләме төзү, нинди дә булса костюм әзерләү.
12. Суда үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен белү, 50 метр араны йөзеп үтү.
13. Шәфкатьлелек акцияләрендә катнашу.
14. Бер яки ике һөнәрне үзләштерү.

ӨЧЕНЧЕ БАСКЫЧ
1. Республбликаның тарихын белү.
2. Халыкара балалар оешмалары турында мәгълүматлы булу.

3. Республикада яшәүче халыкларның милли бәйрәмнәрен, традицияләрен белү.
4. Биш көнлек сәяхәттә катнашу:
лагерьны урнаштыру өчен урын сайлау, аның эшен планлаштыру, утын әзерләү, балта белән дөрес эш итә белү: елганы яки чокырны чыгу өчен җайланма кору:
- өч көнлек азык әзерләү
иртәнге, төшке, кичке аш әзерли белү осталыгыңны күрсәтү: ботаклардан лагерь өчен кирәк булган җиһазны әзерләү:
- туристик төеннәр ясау:
- картаны дөрес итеп укый белү, картадан лагерь урнашкан урынны билгеләү.
5. Суга батучыны коткару кагыйдәләрен белү.
6. 100 метр араны йөзеп үтү, 1 минут су өстендә тору.
7. Сәяхәт өчен аптечка әзерләү, аны дөрес куллану. Ясалма сулыш ясый белү.
8. Башка, аякка, кулга медицина бәйләүе салу.
9. Йөрәк өянәге билгеләрен ачыклау, андый очракларда беренче ярдәм күрсәтү.
10. Көнлек эш тәртибен оештыра белү.
11. Нинди дә булса күңел ачу кичәсе оештыру һәм үткәрү.
12. Тегә белү.
13. Кунак каршылау, дөрес итеп өстәл кору.
14. Спорт ярышларын дөрес итеп үткәрә белү.
15. Урамда һәм бина эчендә төрле хәрәкәтле уеннар үткәрү.
16. Бәйрәмнәрнең, кичәләрнең, бәйгеләрнең сценариясен төзү.
17. Ике һөнәр үзләштерү.
3. «СЕРДӘШ» төркеменә 9-11 сыйныф укучылары керә. КАГЫЙДӘЛӘРЕ:
А) милли үзаңны үстерергә;
Б) кешелекле, намуслы, игътибарлы булырга;
В) җәмгыятьнең иҗади шәхесе булырга омтылырга. Шигаре - "НАМУС, БЕЛЕМ, АКЫЛ - БЕЗНЕҢ МАЯК "
Оешманың төп юнәлешләре:
- "САБАКТАШ" - уку, түгәрәкләр эшен оештыру, киңәшмәләр үткәрү;
- "ҖӘҮҺӘРЛӘР" - ял сәгатьләрен оештыра; "ҖИТЕЗЛӘР" - спорт-сәламәтләндерү эшчәнлеге, гигиена культурасын күтәрү, туристик сәяхәтләр оештыра;
"АК КАЛФАК" - шефлык һәм санитария-гиена эшләрен оештыра;
"ЯШЬ ХУҖА" - гимназияне чиста тоту, аны зәвык белән бизәү турында кайгырта, санитар чәршәбеләрне уздыра;
"ГӨЛБАКЧА" - гимназияне һәм аның тирә-ягын яшелләндерү, табигатьне саклау буенча төрле чаралар уздыра;
- "МӘГЪРИФӘТ" - гимназия стена газетасы эшен оештыра, яңалыклар белән танышу сәгатьләрен тикшерә.
ҮЗИДАРӘНЕҢ ЮГАРЫ ОРГАНЫ КОНФЕРЕНЦИЯ - үзидарәнең югары органы.
Ул елына кимендә бер тапкыр үткәрелә. Конференциядәге делегатлар һәр сыйныфтан ачык сайлау юлы белән сайлана.

Оешманың идарә итүче органы булып ПРЕЗИДЕНТ СОВЕТЫ тора.
Ул айга кимендә бер тапкыр җыела. Президент советына аның министрлары керә.
һәр юнәлешнең җитәкчеләре министлар булып сайлана, һәр юнәлеш айга бер тапкыр үзенең киңәшмәсен үткәрә.
КӨТЕЛГӘН НӘТИҖӘ Мәдәни мирасны өйрәнгән, бер чит телне үзләштергән, камилләшкән иҗади шәхес.
КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ
1. Гимназиядә укучылар үзидарәсе. "Мәгариф", 2004, 6 сан, 70 нче бит.
2. "Эзтабар юлдашы" программасы. Казан, 1999 ел.
3. "Варислар юлдашы" программасы. Казан, 1999 ел.